СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«14» ноябрь 2023 ел** **№ 238**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль урман контроле турында нигезләмәне раслау хакында» Арча район Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 98 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (25.04.2023 № 215 үзгәреш белән)**

Россия Федерациясе Урман кодексының 84 һәм 98 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Арча район Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контроле турында нигезләмәне раслау хакында» Арча район Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 98 номерлы карарына (25.04.2023 № 215 үзгәреш белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары дигән 2 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (htpp://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
_________________ ел, №__
карарына кушымта

**Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары**

Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының түбәндәге индикаторлары билгеләнә:

1) автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнарны кулланганда юл буендагы урман участокларын су басу һәм сазлану;

2) урманнарда янгын һәм санитар куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәмәү;

3) урманнарны файдалы казылмалар табу һәм чыгару өчен куллану;

4) агулы химик препаратлар куллану;

5) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;

6) линия объектларын, шулай ук сусаклагычларын, башка ясалма су объектларын һәм (яки) гидротехник корылмаларны сервитут һәм урманнарны үзләштерү проектын рәсмиләштермичә төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү буенча чаралар үткәрү;

7) урман эшкәртү инфраструктурасын урнаштыру;

8) Россия Федерациясенең Кызыл китабына яки Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр төрләре очрый торган урман участокларын куллану;

9) урман утыртмаларына, үсемлекләр япмасына һәм урман туфрагына зыян китерү;

10) урманнарны төзелеш һәм көнкүреш чүп-чарлары, агач калдыклары, башка төр калдыклар белән чүпләү;

11) урманнарны үзләштерү проектында каралмаган объектлар төзү яки чаралар үткәрү;

12) урманнаны куллану өчен нигез булган документларны (сервитут, урманнарны үзләштерү проекты) рәсмиләштергәндә урман законнарының мәҗбүри таләпләрен үтәмәү.

13) календарь елында урманны торгызу буенча Татарстан Республикасы территориясендә уртача күрсәткеч белән чагыштырганда шул ук вакыт аралыгында эш башкарган контрольдә тотылучы затның утырту (чәчү) урыннары белән сакланып калган үсемлекләр утырту (чәчү) урыннары нисбәтенең биш һәм аннан да күбрәк процентка кимүе.

14) календарь елында шул ук вакыт аралыгында Татарстан Республикасы территориясендә уртача күрсәткеч белән чагыштырганда урман үстерү буенча эш башкарган контрольдә тотылучы затның утырткан яки чәчкән урыннары саныннан булган үсемлекләр яки үсентеләр нисбәтенең биш һәм аннан да күбрәк процентка кимүе.

15) агачны кабул итү, ташу, эшкәртү һәм саклау, агачны исәпкә алу һәм аның белән килешүләр өлкәсендә үткәрелә торган операцияләр күләменең (куб.м) алдагы

календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда бер ел эчендә агачны исәпкә алуның бердәм дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы һәм аның белән килешүләр буенча әзерләнгән һәм сатып алынган агач күләмен тиешле дәрәҗәдә арттыру турында мәгълүмат булмаганда (2023 елдан - урман комплексының федераль дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматлары буенча) өч тапкыр һәм күбрәккә артуы.

16) соңгы өч календарь елда сатылган агачның күләме (куб.м) соңгы өч календарь елда әзерләнгән һәм сатып алынган агачның гомуми күләменнән (куб. м) артуы.